Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение

«Нижневязовская начальная общеобразовательная школа ЗМР РТ»

«Согласовано»

Руководитель МО

_______/ Барскова Ю.А./

Протокол № 1 от

«07» 08 2023 г.

«Утверждаю»

Директор МБОУ «Нижневязовская НОШ» ЗМР РТ

___________/Салахеева Г.А./

Приказ № ______ от

«________» ____________ 20__ г.

# Рабочая программа

Учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)

МБОУ «Нижневязовская НОШ» ЗМР РТ

Салахеевой Гульфии Азамовны

Ф.И.О., категория

литературное чтение на родном языке

предмет, класс. 1 класс

**Аңлатма язуы.**

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле (системно-деятельностный подход) юнәлеш,** ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән рус телле балаларга татар теле укыту системасына да карый. Ягъни, рус телле балаларга татар теле укыту системасының барлык **компонентлары** да: программалар, укыту-методик комплектлары, укыту процессы, белем дәрәҗәсенә контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – бар да бер максатка – **нәтиҗәгә** хезмәт итә.

Тәкъдим ителгән "Гомуми белем бирү мәктәпләрендә рус телле балаларга татар телен комуникатив технология нигездә укыту программасы" психология, педагогика фәннәренең яңа казанышларына таянган һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология нигезендә укыту принципларын исәпкә алып төзелде.

Әлеге программа рус телле балаларга татар теле укыту буенча **эш программаларын** төзү өчен нигез булып тора. Ул укыту предметының мәҗбүри өлешен билгеләгән төп программага таянып төзелде.

Укытучылар э**ш программаларына** мәктәпнең эш үзенчәлеген, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә **сәгатьләр саны бүленешен** һәм материалны **өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә**, **эчтәлекне киңәйтүдә,** шулай ук укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру юлларын ачыклауда **үзгәрешләр** кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының **аңлатма язуында** чагылыш табарга тиеш.

Программа дәүләт контроле һәм белем сыйфатын билгеләү системасы өчен нигез булып тора.

1-4нче сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

- 1. Россия Федерациясенең "Мәгариф турында"гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ "Об образовании в Российской Федерации").

2. Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы (Закон Республики Татарстан "Об образовании" № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).

3. Россия Федерациясенең "Россия Федерациясе халыктелләре турында"гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).

4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 ("Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования").

5. "Татарстан Республикасының халык телләре турында" Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.)

6. "Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасына (1 — 11 нче сыйныфлар), Казан, 2014.Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева

Дәреслекләр :

Р.З.Хәйдәрова,Н.Г.Галиева. Күңелле татар теле. Рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпнең **1 нче сыйныфы** өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүчеләр өчен дәреслек) К.: «Татармультфильм», 2012. ,

Методик ярдәмлек - Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту. Укытучылар өчен методик кулланма. Р.З.Хәйдәрова, Н.Г.Галиева, Л.Ә.Гыйниятуллина.-Казан. Татармультфильм. 2012.

**1)Татар теле укыту максатлары.**

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен укыту **максатлары** берничә аспектны үз эченә ала: **танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.**

**Әдәби уку фәненә характеристика**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

*Үстерү максатының эчтәлеге*

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү, тәрбия максатларын** даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Бу максатлар программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда да беренче планга куела.

*Тәрбияви максатның эчтәлеге*

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Татар теленең грамматикасын өйрәнү процессында эчтәлектә әхлакый проблемалар булган кечкенә

текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була. Шунлыктан тексттагы лексика, грамматика җайлырак истә кала һәм аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый.

*Белем бирү максатының эчтәлеге*

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Укучының белеме дигәндә, без аның аерым сүзләрне яки грамматик категорияне тану, аера белүен генә күзалламыйбыз, ә аларны кулланып сөйләшә алуын күзаллыйбыз. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

I сыйныф – 1 сәгать – 33сәгать

## УКЫТУНЫҢ ГОМУМИ, ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;

– “Татар теле” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

### Укытуның шәхси нәтиҗәләре

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

### Укытуның метапредмет нәтиҗәләре:

Урта белем бирү баскычында татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни, төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*;* укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.
- **Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләре.**
- **Укытуның башлангыч этабы**
- **Тыңлап аңлау**

- Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;
- тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү;
- сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;
- ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.
- **Диалогик сөйләм:**
- Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына жавап бирү һәм сораулар куя белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.
- **Монологик сөйләм**
- Җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;
- тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;
- укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;
- үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә мәгълүмат бирә белү.
- **Уку**
- Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;
- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- тексттагы тыныш билгеләренә карап, тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү, өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганд,а сүзлекләр куллана белү.
- **Язу**
- Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;
- конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

**тематик эчтәлеге**
**1 нче сыйныф (33сәгать)**

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек | Сәг. саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат, |
|---|---|---|
| **Әйдәгез танышабыз**<br>Исәнмесез,хәерле көн,син,кем?<br>Мин,кыз,малай,исем,ничек?Сау булыгыз,балалар,укытучы,әйе,юк,түгел,ул,хәлләр ,рәхмәт,яхшы,Казан,Чаллы,Нурлат,Чистай,Зәй,Әлмәт,шәһәр,авыл,сыйныф,ничә?ничәнче?яшь,1-10га кадәрге саннар,саный,гөмбә,<br>агач,чәчәк. | 2 | Әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, хәлен сорый белү. Әңгәмәдәшеңнең яшәү урынын сорый һәм үзеңнең кайда яшәвең турында хәбәр итә белү.<br>Бер-береңнең яшен, ничәнче сыйныфта укуын сорый, җавап бирә белү. Бергә уйнарга чакыра белү. |
| **Кыргый хайваннар**<br>Поши,куян,аю,бүре,төлке,тиен,керпе,<br>дус,фил,жираф,арыслан,бака,нинди?<br>Су,балык,җир,куркак,хәйләкәр,усал,зур,кечкенә,соры,җырлый. | 3 | Кыргый хайваннарның исемнәрен атый, санын әйтә белү. Кыргый хайваннарның кайда яшәгәнен әйтә, аларны сурәтли белү. |
| **Спорт бәйрәме.**<br>Дустың белән таныштыра белү.Исәнләшү, саубуллашу, кунакка чакыру кебек әйтелмәләрне өйрәнү | 1 | Иптәшеңә командалар бирә белү. Спорт бәйрәмендә нишләгәнеңне әйтә белү.<br>Дустыңны уйнарга чакыра, кем белән уйнаганыңны әйтә белү. |
| **Мәктәптә** Нәрсә?<br>Дәфтәр,китап,бетергеч,каләм,карандаш,бир,әле,мә,кирәк(кирәкми). Тәнәфес,дәрес,рәсем,татар теле,рус теле,укый, яза,рәсем ясый,мәктәп,бар,бүген,укучы,<br>өстәл,белән,астында,<br>өстендә,ничәле?<br>дүртле,бишле,өчле,ала,матур,чиста. | 2 | Уку-язу әсбапларының исемнәрен әйтә, үзеңә сорап ала, иптәшеңә тәкъдим итә, кирәклеген, санын әйтә белү. Мәктәптәге уку хезмәтен атый, үзеңнең, иптәшеңнең ничек укуын әйтә белү. Предметларның урынын әйтә белү (китап өстәлдә) |
| **Йорт хайваннары һәм кошлары**<br>Кош,йөгерә,сикерә,йөзә,оча,нишли?<br>Алар,бас,утыр,гафу<br>ит(егез),ярый,тиз,әкрен,көчле,җиңел,авыр,көлә,<br>ярыш,ярыша,җиңә,җиңүче.<br>Сыер,сарык,ат,кәҗә,дуңгыз,песи,эт, | 2 | Йорт хайваннарының һәм кошларының исемнәрен әйтә, саный, яшәү урынын әйтә белү |

| | | |
|---|---|---|
| әтәч,тавык,каз, үрдәк, чеби,бәбкә, кая?кемгә? кайдан?кайчан? күл,кайта | | |
| **Бакчада**<br>Кишер,шалкан,кыяр,бәрәңге,суган,кәбестә,кабак, алма,җиләк,җир,ялкау,эшчән,сибә,җыя,бакча,ярат а,үсә,чәчә,казый,уңыш. | 4 | Яшелчә һәм җиләк-җимеш исемнәрен, санын, аларның төсен, тәмен әйтә, аларны сорап ала белү. Бакчада нәрсә үскәнен, нинди эшләр эшләгәнеңне әйтә белү.<br>Нәрсә яратканыңны, яратмаганыңны әйтә, сорый белү. Хезмәтенә карап, геройга бәя бирә белү. |
| **Кыш**<br>Кыш фасылы турында сөйли белү | 4 | Кыш билгеләрен әйтә, сорый, һава торышын тасвирлый белү. Яңа ел бәйрәме турында сөйли белү. Бәйрәмгә барганыңны, бәйрәмнең кайда булганын әйтә белү. Кышкы уен төрләрен әйтә, уенга чакыра белү. Чана, чаңгы, тимераякларның барлыгын, юклыгын, нәрсә белән шуганыңны әйтә белү. |
| **Сәламәт бул** !<br>Тән әгъзаларын атаучы лексика;дару,авырта,сабын,тарак,сөлге, теш щёткасы,юына,чистарта,юа. | 3 | Тән әгъзаларының исемнәрен атый, кайсы җирең авыртканын сорый, әйтә белү. Сәламәт булу өчен, киңәшләр бирә белү. Авыру кешенең хәлен сорау, аңа дару, чәй тәкъдим итә белү. Шәхси гигиена предметларының исемнәрен, аларның барлыгын, юклыгын, кирәклеген әйтә, аларны сорап ала белү. |
| **Безнең гаилә**<br>Бер-береңә эш куша белү. | 3 | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, үз гаиләң турында сөйли белү, иптәшеңнең гаиләсе турында сорый белү. Язгы көнне сурәтләп сөйли белү. Яз фасылының ошаганын, ошамаганын әйтә белү. Бәйрәм белән котлый, кемгә бүләк бирүне әйтә белү. |
| **Кунакта**<br>Бәйрәмнәргә чакыра белү | 4 | Татар халык ашларының исемнәрен, ризыкларның тәмле булуын, нинди ризыклар яратканыңны, нинди ризык кирәк икәнен, нәрсә белән чәй эчкәнеңне әйтә белү. Кунакларны каршы ала, аларны табынга чакыра белү. Туган көн турында сөйли, туган көн белән котлый белү. |
| **Кибеттә. Киемнәр кибетендә.**<br>Кием сатып ала белү. | 1 | Ашамлыклар исемнәрен,нәрсә ашаганыңны, эчкәнеңне әйтә, кибеттә сатып ала белү. Савыт-саба исемнәрен дөрес әйтә белү. Киемнәрнең исемен, төсен, нинди кием кигәнеңне әйтә белү. |
| **Без шәһәрдә яшибез.**<br>Шәһәр турында сөйли белү күнекмәләре.<br>Үз гаиләң турында сөйли белү. | 1 | Нинди республикада яшәгәнеңне, Татарстан шәһәрләре исемнәрен әйтә белү. Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. |
| **Җәй**<br>Җәй фасылы турында сөйли белү. Балык тота,су коена,саф һава,гөмбә. | 3 | Җәй билгеләрен әйтә белү. Дусларны Сабантуй бәйрәменә чакыра, бәйрәмдә нишләгәнеңне әйтә белү. |

**Әдәби укудан календарь-тематик план**

| № | № бүлек | Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы | Сәг. саны | Көтелгән нәтиҗәләр | | | Укучылар эшчәнлеге | Үткәрү вакыты План | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Предмет нәтиҗәсе | Метапредмет нәтиҗәсе | Шәхси нәтиҗә | | | |
| **1.Әйдәгез танышабыз (2сәг)** | | | | | | | | | |
| 1 | 1 | Әйдәгез танышабыз! | 1 | Өйрәнелгән лексиканы диалогик сөйләмдә куллану | Әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра белү. Сорау куя, әңгәмәдәшеңнең хәлен сорый, кире кага, раслый белү | Уңай мотив тудыру, уку теләге булдыру | Сорауларга җавап бирү күнекмәләре | | |
| 2 | 2 | Татарстан шәһәрләре | 1 | Шәһәр исемнәрен әйтә белү. Әңгәмәдәшеңнең яшәү урынын сорый һәм үзеңнең кайда яшәвең турында хәбәр итә белү | Сөйләмдә куллана белә. Син кайда яшисең? Мин Казанда яшим Татарстан, Россия шәһәр исемнәрен әйтү. | Туган якка мәхәббәт уяту | Практикада куллану. Шәһәрләрне картадан күрсәтү | | |
| **2.Кыргый хайваннар.(3 сәг)** | | | | | | | | | |
| 3 | 1 | Кыргый хайваннар. | 1 | Өйрәнелгән лексиканы кулланып җавап бирә белү | Кыргый хайваннарның исемнәрен атый, саный, яшәү урыннарын әйтә белү | Әхлакый сыйфатлар формалаштыру | Рәсемнәргә карап,сорау һәм җаваплар бирү | | |
| 4 | 2 | Рус халык әкияте”Төремкәй”. | 1 | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана | Аңлап уку күнекмәләре булдыру | Дуслык, туганлык кыйммәте формалаштыру | Сорау җөмләләрне аңлап, уңай, кире җавап бирү күнекмәләре булдыру | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | алу. | | | | | |
| 5 | 3 | “Төремкәй” әкиятен сәхнәләштерү. | 1 | “Төремкәй” әкияте белән танышу, сәхнәләштерергә әзерләнү | Әкиятне аңлап уйный белә | | Белемнәрне практикада куллану | | |
| **3.Спорт бәйрәме.(1 сәг)** | | | | | | | | | |
| 6 | 1 | Спорт бәйрәме. | 1 | Бер-береңнән мәгълүмат, интервью ала белү | Сорауларга тулы җавап бирә. | Мәктәпкә уңай мөнәсәбәтле укучы карашы формалаштыру | Белемнәрне практикада куллану. | | |
| **4.Мәктәптә (2 сәг)** | | | | | | | | | |
| 7 | 1 | Уку-язу әсбаплары | 1 | Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана алу | Бу нәрсә? сорауларына дөрес җавап бирү | | Сорауларга тулы җавап бирү | | |
| 8 | 2 | Без дәрестә. | 1 | Мәктәптәге уку хезмәтен атый, үзеңнең, иптәшеңнең ничек укуын әйтә белү | Дөрес һәм пөхтә яза белә. Уку-язу әсбапларының исемнәрен әйтә, иптәшенә тәкъдим итә, сорап ала белү | Уңай мотив тудыру, уку теләге булдыру | Монологик сөйләмгә чыгу | | |
| **5.Йорт хайваннары һәм кошлары.(2 сәг)** | | | | | | | | | |
| 9 | 1 | Йорт хайваннары һәм кошлары. | 1 | Йорт хайваннары һәм кошларның исемнәрен атый, яшәү урыннарын әйтә, аларны характерлый белү | Хикәя җөмләләр төзи. Бу нәрсә? Бу аю. Ул урманда яши (яшәми). Аю зур, усал | Йорт хайваннарына сак караш тәрбияләү | Үрнәк буенча җөмләләр төзү | | |
| 10 | 2 | “Без йоклыйбыз”тексты | 1 | Без йоклыйбыз”тексты белән танышу | Укыганның эчтәлегенә төшенү. | | Эчтәлек буенча тәрҗемә. | | |
| **6.Бакчада (4 сәг)** | | | | | | | | | |
| 11 | 1 | Яшелчәләр. | 1 | Яшелчә исемнә-рен, санын, алар-ның төсен, тәмен | Яшелчә исемнәре белән танышыру | Хезмәтне яратырга өндәү | Рәсем буенча җөмләләр төзү | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | әйтә, аларны со-рап ала белү. | | | | | |
| 12 | 2 | Җиләк-җимешләр. | 1 | Нинди җиләк-җимеш яратка-ныңны әйтә белү. Базарда яшелчә, җиләк-җимеш сатып ала белү | Җиләк-җимеш исемнәре белән танышыру | | Танып – белү активлыгын үстерү | | |
| 13 | 3 | Рус халык әкияте "Шалкан" | 1 | Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана ала | Яңа сүзлләр белән танышу | Дуслык, туганлык кыйммәте формалаштыру | Сорауларга тулы җавап бирү | | |
| 14 | 4 | "Шалкан"әкиятен сәхнәләштерү | 1 | Рус халык әкияте "Шалкан" әкиятен сәхнәләштерергә әзерләнү | Әкиятне аңлап уйный белә | | Белемнәрне практикада куллану | | |
| 7.**Кыш. (4 сәгать )** | | | | | | | | | |
| 15. | 1 | Кыш билгеләре. | 1 | Кыш билгеләрен әйтә белү | Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана алу | | Монолог төзү | | |
| 16 | 2 | "Кыш бабай"шигыре. | 1 | Яңа ел, чыршы, кыш бабай һәм кар кызы исемнәрен атый белү. Яңа елга кем килә.Кыш бабай, кар кызы килә. Кыш бабай бүләк алып килә– җөмләләрен үзләштерү | Кыш бабайны каршылау. Өйрәнгән лексиканы ныгыту | Мәктәпкә уңай мөнәсәбәтле укучы карашы формалаштыру | Әңгәмәдә,бәйләне шле сөйләмдә өйрәнгән лексиканы куллану | | |
| 17 | 3 | Кышкы уеннар. | 1 | Кышкы уен төрләрен әйтә белү, уенга | Уеннар турында сөйли белү | Сәламәтлекне сакларга өндәү | Диалог төзү | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | чакыра белү | | | | | |
| 18 | 4 | Бәйрәмнәрдә. | 1 | Бәйрәмгә чакыра, бәйрәм белән котлый белү | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Милләтнең,Ватанның бер вәкиле булуың белән горурлану | Тәрҗемә итү, җөмләләр төзү | | |
| **8.Сәламәт бул!(3 сәг)** | | | | | | | | | |
| 19 | 1 | Тән әгъзалары исемнәре. | 1 | Лексик берәмлекләрнеүзл әштерү. | Тән әгъзалары исемнәрен атый белү | | Сораулар ярдәмендә сөйли белү | | |
| 20 | 2 | Сәламәт булу өчен киңәшләр. Диалог. | 1 | Лексик берәмлекләрне үзләштерү, сәламәт булу өчен киңәшләр бирә белү. | Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана ала. | Сәламәтлекне сакларга өндәү | Тәрҗемә итә белү. | | |
| 21 | 3 | Шәхси гигиена предметлары. | 1 | Сорау әйтү. Сузык авазларны дөрес әйтә белү | Шәхси гигиена предметлары белән танышу | | Сораулар төзү. Сорауга төгәл җавап бирү. | | |
| **9.Гаилә.(3 сәг)** | | | | | | | | | |
| 22 | 1 | Гаилә. | 1 | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, гаиләдә кемнәр, ничә кеше барлыгын әйтә белү | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, үз гаиләң турында сөйли белү | Гаиләгә, туган илгә карата мәрхәмәтлеле булырга өндәү | Бәйләнешле сөйләү күнекмәләре | | |
| 23 | 2 | Фатих Кәрим “Яз җитә” | 1 | Шигырь белән танышу. Сөйләмнең сәнгатьлелеген үстерү | Сәнгатьле итеп укый белә. | Мәктәпкә уңай мөнәсәбәтле укучы карашы формалаштыру | Эшчәнлеккә үзбәя куя белү. Ятлау. | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24 | 3 | “Тәмле сүзләр” | 1 | Сөйләмдә тәмле сүзләр куллана белү.Сүзләрдә басымны дөрес кую | Тыныч йокы! Хәерле иртә! (көн,кич) Рәхим итегез! Сау булыгыз! | Әхлакый сыйфатлар формалаштыру | Өйрәнгән грамматик структураларны бәйләнешле сөйләмдә файдалану күнекмәләрен булдыру. | | |
| **10.“Кунакта” (4 сәг)** | | | | | | | | | |
| 25 | 1 | Татар халык ашлары | 1 | Татар халык ашлары белән танышу, исемнәрен атый, нинди ашлар пешергәнне әйтә белү. | Татар халык ашлары атамала рын белү. *Әни бә-леш пешерә. Гөбәдия бик тәмле* сөй-ләмдә куллану | Милләтнең,Ватанның бер вәкиле булуың белән горурлану | Тәрҗемә итә белү күнекмәләре Сорауларга җаваплар бирә белү күнекмәләре | | |
| 26 | 2 | Туган көн-зур бәйрәм. | 1 | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана ала. | Дуслык, туганлык кыйммәте формалаштыру | Дәреслек белән эшли белү күнекмәләре | | |
| 27 | 3 | Ашамлыклар. | 1 | Ашамлыклар исемнәрен әйтә белү, аларның тәмен әйтү, нинди ашамлык яратканыңны әйтә белү | Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана алу | | Үрнәк буенча сөйләү күнекмәләре | | |
| 28 | 4 | Бари Рәхмәт. “Аш вакыты” | 1 | Сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру | Бари Рәхмәт “Аш вакыты” | Әхлакый сыйфатлар формалаштыру | Татарча дөрес уку күнекмәләре | | |
| **11.Кибеттә. Киемнәр кибетендә.(1сәг)** | | | | | | | | | |
| 29 | 1 | Киемнәр. | 1 | Кием исемнәрен әйтә белү, алар-ның төсен,нинди | Кием исемнәре белән таныштыру | | Монологик сөйләм күнекмәләре. | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | кием яратканың-ны әйтү. | | | | | |
| **12.Безнең шәһәр.(1 сәг)** | | | | | | | | | |
| 30 | 1 | Безнең шәһәр. | 1 | Шәһәрләрне картадан күрсәтү аша шәһәр атамаларын истә калдыру, дөрес әйтү.Туган шәһәрең турында сөйли белү | Картадан Татарстан шәһәрләрен күрсәтә һәм исемнәрен атый белә. | Милләтнең,Ватанның бер вәкиле булуың белән горурлану | Карта белән эшли белү күнекмәләре | | |
| **13.Җәй ( 3 сәг)** | | | | | | | | | |
| 31 | 1 | Җәйге ял | 1 | Җәйге табигать, турында сөйли белү. Лексика: җәй, көн, елга, күл, җиләк, гөмбә, Сабантуй | Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллана алу | Кеше фикеренә карата ихтирамлы караш булдыру | Монологик төзү | | |
| 32 | 2 | Габдулла Тукай.”Бала белән күбәләк” | 1 | Йөгерек, аңлап уку. | Габдулла Тукай ”Бала белән күбәләк”әсәре белән танышу | Мәктәпкә уңай мөнәсәбәтле укучы карашы формалаштыру | Дәреслек белән эшли белү | | |
| 33 | 3 | Без Сабантуйга барабыз. | 1 | Сабантуй турында сөйли белү. | Татар хал-ның милли бәйрәме – Сабантуй белән таныштыру | | Дәреслек белән эшли белү. | | |

**1нче сыйныф**

1. Исемнәрнең берлек һәм күплек саны.
2. Исемнәргә **кем? нәрсә?** сорауларын куя белү.
3. Исемнәрнең 1, 2 затта берлектә тартым белән төрләнеше белән таныштыру.
4. Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләре белән таныштыру.
5. Микъдар һәм тәртип саннары белән таныштыру (1-10 саннары).
6. Зат алмашлыкларын берлектә баш, иялек, юнәлеш килешләрендә сөйләмдә куллану белән таныштыру.
7. **Бу** күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану.
8. **Кая? Кайда? Кайдан?** сорауларына җавап бирә белү.
9. **Ничә? Ничек?Нинди?** сорауларына җавап бирә белү.
10. Хәзерге заман хикәя фигыльнең 1,2,3 зат формаларын берлектә сөйләмдә куллану.
11. Боерык фигыльнең II затта берлек сан формасы белән таныштыру.
12. **-мы/-ме**, **түгел, әле** кисәкчәләрен сөйләмдә куллану.
13. **Белән** бәйлеген исем белән сөйләмдә куллану.
14. **Һәм** теркәгечен сөйләмдә куллану.
15. **Сыйфат+исем** төзелмәсен сөйләмдә куллану.
16. **Сан+исем** төзелмәсен сөйләмдә куллану.
17. 

**Орфографик һәм орфоэпик минимум.**

1. Сузык һәм тартык авазлар, аларның аермасы. Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аерырга өйрәнү.
2. Татар һәм рус телләрендәге сузык һәм тартык авазларны чагыштырып, дөрес әйтә белү, транскрипция билгеләре белән таныштыру.
3. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, иҗекләп икенче юлга күчерү. Иҗек калыпларына нигезләнгән уку кагыйдәләрен гамәли үзләштерү.
4. Озын һәм кыска сузыкларны сүзләрдә дөрес итеп әйтә белү.
5. Татар хәрефләренең кабул ителгән формаларын дөрес язу.
6. Сүз басымы. Сүзләрдә басымны дөрес кую.
7. Хикәя һәм сорау җөмләләрне интонацион яктан дөрес әйтергә гадәтләндерү. Җөмлә ахырында дөрес тыныш билгеләрен куеп язарга күнектерү.
8. Ялгызлык исемнәрен баш хәрефтән башлап язарга өйрәнү.
9. Матур һәм дөрес язу күнекмәләре булдыру.

Боеру максаты белән әйтелгән җөмләләрне аңларга өйрәнү.

**Укыту процессының материаль -техник тәэмин ителеше**

-Ноутбук

**Дидактик һәм методик тәэмин ителеш**

| Дидактик тәэмин ителеш | Методик тәэмин ителеш |
|---|---|
| 1.Татарский язык. 1 класс: учебник для четырехл. нач. шк. В 2 ч. Р.З.Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина. – Казань: Татармультфильм, 2015.<br>2. Р.Р.Нигъматуллина «Татар телен өйрәнүчеләр өчен кагыйдәләр һәм күнегүләр җыентыгы 1,2 кисәк», Яр Чаллы, 2012.<br>3.Б.Рәхмәт “Сабан туенда”. Шигырьләр. – Казан: Тат.кит. нәшр., 2010.<br>4.Нәниләргә бүләккә. Җыентык. Табышмаклар, такмаклар, әкиятләр, шигырьләр, кыска хикәяләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2011.<br>5.Р.Миңнуллин “Алма бабай”. Балалар өчен шигырьләр, әкиятләр. – Казан: “Мәгариф”, 2012.<br>6.Орфографик, орфоэпик һәм башка төр сүзлекләр. | 1.Пособие для учителей, работающих с русскоязычными учащимися по учебнику “Күңелле татар теле”. – Казан: Татармультфильм, 2013.<br>2. А.Ш.Асадуллин, Р.А.Юсупов. «Рус телле балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре» Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2010.<br>3. Р.З.Хайдарова. «Научно-педаго-гические аспекты билингвального образования в Республике Татарстан», Набережные Челны, 2012.<br>4. Р.З.Хайдарова «Сборник ситуативных упражнений по татарскому языку для русскоязычных учащихся», Набережные Челны, 2014.<br>5. Ф.Ф.Харисов «Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре», Казан, “Мәгариф”, 2010.<br>6.Ч.М.Харисова «Тренировочные упражнения по обучению татарскому произношению», Казань, «Магариф», 2010. |

**Интернет ресурслар:**

1. tatarile.org/video- татар фильмнары, мультфильмнары, тапшырулар
2. mon.tatar.ru – ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайты
www.edu.tatar.ru --- электронное образование РТ
3. http://mon.tatar.ru/ - министерство образования и науки РТ